КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 11 сентябрь г.Казань № 685

2026 елга һәм 2027 һәм 2028 еллар план чорына алкогольдән, наркотиктан яисә башка токсик матдәләрдән исерек хәлендәге затларга ярдәм күрсәтү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча хезмәт күрсәтү кыйммәте нормативын раслау турында

«Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына алкогольдән, наркотиктан яисә башка токсик матдәләрдән исерү халәтендә булган затларга ярдәм күрсәтү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2017 елның 10 июлендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, җирле үзидарә органнары тарафыннан алкогольдән, наркотиктан яисә башка токсик матдәләрдән исерү халәтендә булучы затларга ярдәм күрсәтү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына бирелә торган субвенцияләр күләмен исәпләү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

2026 елга һәм 2027 һәм 2028 еллар план чорына алкогольдән, наркотиктан яисә башка токсик матдәләрдән исерек хәлендәге затларга ярдәм күрсәтү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча хезмәт күрсәтү кыйммәте нормативын;

2026 елга һәм 2027 һәм 2028 еллар план чорына алкогольдән, наркотиктан яисә башка токсик матдәләрдән исерү халәтендә булучы затларга ярдәм күрсәтү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча хезмәт күрсәтү кыйммәте нормативына инфраструктура белән тәэмин ителүдәге аермалыкларны һәм хезмәт күрсәтү кыйммәте нормативы мәгънәсенә йогынты ясый торган башка факторларны исәпкә ала торган корректировкалау (төзәтү) коэффициентларын;

2026 елга һәм 2027 һәм 2028 еллар план чорына алкогольдән, наркотиктан яисә башка токсик матдәләрдән исерү халәтендә булучы затларга ярдәм күрсәтү өчен махсуслаштырылган оешмаларда койкалар санын.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2026 елга һәм 2027 һәм 2028 еллар план чорына алкогольдән, наркотиктан яисә башка токсик матдәләрдән исерек хәлендәге затларга ярдәм күрсәтү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча хезмәт күрсәтү кыйммәте нормативын раслау турында» 2024 ел, 10 сентябрь, 759 нчы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 11 сентябрь, 685 нче
карары белән расланды

2026 елга һәм 2027 һәм 2028 еллар план чорына алкогольдән, наркотиктан яисә башка токсик матдәләрдән исерек хәлендәге затларга ярдәм күрсәтү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча хезмәт күрсәтү кыйммәте
нормативы

| Хезмәт күрсәтү исеме | Норматив, койка көненә сум | | |
|---|---|---|---|
| | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел |
| Алкогольдән, наркотиктан яисә башка токсик матдәләрдән исерек хәлендәге затларга ярдәм күрсәтү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру | 1 082,95 | 1 087,43 | 1 088,44 |

______________________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 11 сентябрь, 685 нче
карары белән расланды

2026 елга һәм 2027 һәм 2028 еллар план чорына алкогольдән, наркотиктан яисә башка токсик матдәләрдән исерү халәтендә булучы затларга ярдәм күрсәтү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча хезмәт күрсәтү кыйммәте нормативына инфраструктура белән тәэмин ителүдәге аермалыкларны һәм хезмәт күрсәтү кыйммәте нормативы мәгънәсенә йогынты ясый торган башка факторларны исәпкә ала торган корректировкалау (төзәтү) коэффициентлары

| Муниципаль берәмлек исеме | Корректировкалау (төзәтү) коэффициенты | | |
|---|---|---|---|
| | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел |
| Азнакай муниципаль районы | 1,512358 | 1,513257 | 1,513571 |
| Әлмәт муниципаль районы | 1,512358 | 1,513257 | 1,513571 |
| Бөгелмә муниципаль районы | 1,512358 | 1,513257 | 1,513571 |
| Алабуга муниципаль районы | 1,512358 | 1,513257 | 1,513571 |
| Зәй муниципаль районы | 1,512358 | 1,513257 | 1,513571 |
| Зеленодольск муниципаль районы | 1,556124 | 1,556844 | 1,556998 |
| Лениногорск муниципаль районы | 1,512358 | 1,513257 | 1,513571 |
| Түбән Кама муниципаль районы | 1,512358 | 1,513257 | 1,513571 |
| Чистай муниципаль районы | 1,512358 | 1,513257 | 1,513571 |
| Яр Чаллы шәһәре | 0,963704 | 0,965151 | 0,966026 |
| Казан шәһәре | 0,963786 | 0,965226 | 0,966107 |

_________________________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 11 сентябрь, 685 нче
карары белән расланды

2026 елга һәм 2027 һәм 2028 еллар план чорына алкогольдән, наркотиктан яисә башка токсик матдәләрдән исерү халәтендә булучы затларга ярдәм күрсәтү өчен махсуслаштырылган оешмаларда койкалар саны

| Муниципаль берәмлек исеме | Койкалар саны | | |
|---|---|---|---|
| | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел |
| Азнакай муниципаль районы | 10 | 10 | 10 |
| Әлмәт муниципаль районы | 10 | 10 | 10 |
| Бөгелмә муниципаль районы | 10 | 10 | 10 |
| Алабуга муниципаль районы | 10 | 10 | 10 |
| Зәй муниципаль районы | 10 | 10 | 10 |
| Зеленодольск муниципаль районы | 10 | 10 | 10 |
| Лениногорск муниципаль районы | 10 | 10 | 10 |
| Түбән Кама муниципаль районы | 10 | 10 | 10 |
| Чистай муниципаль районы | 10 | 10 | 10 |
| Яр Чаллы шәһәре | 20 | 20 | 20 |
| Казан шәһәре | 40 | 40 | 40 |

______________________________